1941 елның 22 июнь иртәсе тарихта онытылмас авыр истәлек калдырды. Бу көнне Германия гаскәрләре илебезгә һөҗүм итте.

Мәмәшир авылы да Бөек Җиңүгә үзеннән лаеклы өлеш кертте. 24 июнь көнне кичке 10 сәгатьтә фронтка җибәрү өчен 165 ир-егет чакырыла. 25 июньдә яңадан 40 кешене хәрби комиссариат чакыртып ала.

Аңарчы хәрби хезмәт үткән запастагы солдатлар уенга (сборга) чакырыла башлый. Шул ук елның 30 маенда авылдан 12 кеше чыгып китә, шул китүдән уникесе дә әйләнеп кайта алмый.

Сугыш кырларында дошманга каршы сугышкан авылдашларыбыз:



**Таһиров Габделбәр һәм Усманов Ислам**



**Шаһиев Илһаметдин (сулда)**



**Зәйниев Таһир**



**Закиров Хәмәтсабир (уңда)**


Ут эченнән авылга килгән хатларның һәркайсында басып алучыларга нәфрәт, дошманның җиңеләчәгенә ышаныч ята.



ПОЧТОВАЯ КАРТОЧКА
CARTE POSTALE

Тат. республика
ст. Кукмор Кукморский р-н
д. Мамашир
Сафиуллиной Ходы

1665 полевая почта
часть 661 Сафиуллин Мамашир
жан




Сафиуллина Бәдехиягә әтисе Мөхәммәтҗан язган хат музейда саклана.


Ул анда сул аягының яралануы, хәзер госпитальдә ятуы турында хәбәр итә. Ләкин, башка күп авылдашлар кебек. Мөхәммәтҗан абзый да яу кырында ятып кала.

Шулай ук Шәфигуллин Хәлиуллаthe да фронттан гаиләсенә язган хатлары музейда саклана.





Сугыш вакытында авылга әле бер, әле икенче гаиләгә «Батырларча һәлак булды» дигән җанны өшеткеч кара мөһерле кәгазь килеп тора.



НКО
Воинская часть
7/361 „А"
4.04.43.

Гражданке Мамсевой

Сообщаю, что Мухлисуллин Зиннат в бою с немецкими оккупантами 18.02.43 г. героически погиб и 19.02.43 г. похоронен в братской могиле. Вам предан Воинской присяге смелый, героический, способный в бою. За смерть Зинната поплатились немцы десятком зверских жизней ганцев и фрицев.

Командир части 75361 „А"
Капитан

21/IV 43

**Мөхлисуллин Зиннәт Мөхлисулла улы**
**гаиләсенә килгән “кара кәгазь”**

Бер йорттан чыгып киткән Муллахмәт, Галиәхмәт, Хаҗиәхмәт Габдрахмановларның берсе дә кайтмый. Сәмигуллиннар йортыннан биш кеше— Әхмәдулла, Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Шәфигулла, Наумир чыгып китә. Шуның өчесе ятып кала. Кызганыч, мондый гаиләләр күп була.

Авылдашларыбыздан — старшина Гафият Гарифуллин. Саттар Кәримуллин, Габделбәр Таһиров, Каюм Мирзагаянов фронтның утлы юлларын күп урыйлар, хөкүмәт бүләкләренә лаек булалар. Гыйльмулла Максутов, Вакыйф Зыятлинов, Нәфикь Галимов, Хәлиулла Кәримуллин һәм башка күпләр фронтта сәламәтлекләрен калдырдылар.

Актив хәбәрче **Наумир ага Сәмигуллин**ның саваплы һәм изге эше аерым игътибарга лаек.

1943 елнын гыйнварында Казан елга техникумының 17 яшьлек студентын армиягә алалар. Кече лейтенант Сәмигуллин үзенең автоматчылар взводы белән Балтик буендагы Шауляй, Лиепая, Клайпеда шәһәрләрен азат итешә. Ике тапкыр яралана. Беренчесе җиңел яра булганга, сугыштан чыкмый. Икенчесендә авыр яра ала. Бу хакта Наумир абый үзе «Татарстан яшьләре» газетасының 1988 елгы 7 август санында менә нәрсәләр яза: «1944 елның 5 ноябрь кичендә взводтан сафта калган 6 кешелек группа яңа приказ алды: дошманнан тартып алынган траншеяның уң ягын сакларга уңайлы позицияләрен кире кайтарырга омтылып, төн ышыгында безгә таба шуышкан немецларны тоткарлап тордык, атакага күтәрелеп, аларны чигенергә мәҗбүр иттек. Бу төнге мәхшәрдә ярдәмчем Аксенов, якташым Рәхмәтуллин һәм үзем авыр яраландык. Үземнең хәлне соңрак белдем: әлеге төнге бәрелештә дошман ыргыткан агач саплы кул гранатасы бик якында шартлаудан минем ике калак сөяге, баш сөяге зарарланган, бер кабырга, уңъяк җилкәдә умрау сөяге сынган, ә дүрт кисәк металл кыйпылчыгы үпкәгә үк кереп калган...»


1945 ел. Хирург Векличева С.Н., Н.Сәмигуллин эв. госпитальдә

Киләчәгебез өчен тормышларын биргән авылдашларыбызның якты истәлеген мәңгеләштерү, аларны барлау, исәннәргә җиткерү буенча Наумир абый олы эш башкара.

Аның сугыш истәлекләре республика, шәһәр, район газета-журналларында әледән-әле дөнья күрә. Аларда авылдашларыбызның яу кырындагы каһарманлыгы сурәтләнә.


Изге көрәштә шәһит киткәннәрнең гомерлек батырлыгын данлап мәктәп каршында һәм авыл уртасында һәйкәл тора.







**1990 елларда һәм 2008 елда авылда һәйкәл каршында Җиңү көнен бәйрәм итү**



# “Үлеп терелгән” солдат

1943 елның январь башында Закирҗан абый һәм Саҗидә апалар гаиләсе фронттан кайгылы хәбәр ала. Анда гвардия рядовое **Габделфәрт Закирҗанов**ның батырларча һәлак булуы турында әйтелә.

Габделфәрткә бары 17 яшь тулган вакытта сугыш башлана. 1942 елның 21 августында ул үзе теләп хәрби хезмәткә китә, артиллерист һөнәрен үзләштерә.

...Менә туганнарына “кара кәгазь” килә. (“Хәтер китабы”на аның да исеме кертелгән. “Погиб 17 ноября 1943 года. Захоронен: Витебская область, Лиозненский район, дер. Заболотье”,-диелгән анда.) Газизләренең Белорусия җирләрендә күмелүе турындагы хәбәрне алган әти – әнисе һәм туганнары югалып кала. Кара кәгазь килгән көннән санап китеп, тиешенчә өчесен, җидесен үткәрәләр.

Көннәрдән бер көнне аларның газиз Габделфәртләре кайтып төшә.

Хәл кергәч, юлдан кайткан солдатны ашарга утырткач, туганнары Габделфәрт абыйга бер – бер артлы сорау яудырырга тотына. Ул сөйли: “43нең кышы аеруча салкын килде. Мин солдатларны ашатырга барырга тиеш идем. Килдем, өләштем. Фашистлар аяз көндә яшен суккан шикелле пәйдә булдылар. Аягым нык яраланды. Аңыма килгәндә, ниндидер юнәлештә мине өстерәп баралар иде. Аннары башыма китереп сукты – пленга “төшеп баруым” икән югыйсә. Берзаман күрәм, алда – сазлык, төшеп чумдык без бу сазлыкка. Аска өстери башлады, ярар, мин әйтәм, сазлыкта калу пленга төшүдән артык. Торам посып, һаман аска суыра, инде муеннан чумдым. Юк, фашистлар мине күрмичә китеп бардылар.”

Иптәшләре күреп, коткарып кала Габделфәрт абыйны. Казанга госпитальгә озаталар, үз частендә булмагач, аны үлгән дип уйлап, өенә кара кәгазь җибәрәләр.

Аягы төзәлгәч, янә сугыш кырына юл тота ул, дошманнарны Белоруссия җирләреннән куып чыгаралар. 1944 елда Габделфәрт абый тагын яралана, Смоленск шәһәре госпиталенә китерелә. Монда 3 ай дәвалана, чыккач, Литва-Латвия фронтында илебез җирләрен азат итүдә үзеннән зур өлеш кертә.

Җиңү көнен Габделфәрт абый Көнчыгыш Пруссиядә каршы ала, ләкин японнарга каршы сугышка китә. Моннан соң да әле ул 2 ел Свободный шәһәрендә хезмәт итә. 1947 елның январь аенда гына туган авылына әйләнеп кайта.

Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен хөкүмәтебез Габделфәрт абыйны ”За боевые заслуги“, ”За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.”, “За Победу над Японией”, Жуков медале белән бүләкли.

Бүгенге көндә ул инде безнең арада юк.

Әнә шундый үлеп терелгән кеше Габделфәрт Закирҗанов!



**Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан үткәрелгән үзешчәннәр смотрында Габделфәрт абый –лауреат**

## Алар Ватан өчен гомерләрен бирделәр. Мәңгелек дан аларга!

### Мәмәшир авылы буенча:

1. Абдуллин (Шәрәфиев) Гарәфи И. улы
2. Абдуллин Бәдыйк Абдулла улы
3. Абдуллин Мотыйгулла Абдулла улы
4. Абдуллин Рәхимҗан Габдулла улы
5. Абдуллин Сәмигулла Абдулла улы
6. Абдуллин Минемулла Абдулла улы
7. Әхмәтшин Әхмәтгали Әхмәтша улы
8. Әхмәтгалиев Гәрәй Әхмәтгали улы
9. Әхәтов Габделгани Әхәт улы
10. Әхәтов Кави Әхәт улы
11. Әхәтов Кәрим Әхәт улы
12. Әшрәфҗанов Йосыфҗан Әшрәфҗан улы
13. Әшрәфҗанов Мирзагаләм Әшрәфҗан улы
14. Абдуллин Мөхлисулла Абдулла улы
15. Абдуллин Нурулла Абдулла улы
16. Бәкеров Гали Бәкер улы
17. Бакиров (Сабирҗанов) Галимулла Сабирҗан улы
18. Бакиров Хөсәен
19. Бәхтигәрәев Әхмәтгәрәй Бәхтигәрәй улы
20. Вәлиуллин Гарифулла Вәлиулла улы
21. Вәлиуллин Ибраһим Вәлиулла улы
22. Вахитов Габделхәй Вахит улы
23. Вәлиев Ибраһим Вәли улы
24. Вәлиев Сабирҗан Хәмәтдин улы
25. Габдрахманов Муллахмәт Габдрахман улы
26. Габдрахманов Галимулла (Таң)
27. Габдрахманов Галиәхмәт Габдрахман улы
28. Габдрахманов Хаҗиәхмәт Габдрахман улы
29. Габдрахманов Ибраһим Габдрахман улы
30. Габидуллин Зиннәтулла Габидулла улы
31. Габидуллин Зәкиулла Габидулла улы
32. Габитов Габдулла Габит улы
33. Габитов Вәккас Габит улы
34. Гайфетдинов Әгъләметдин Гайфетдин улы
35. Галимов Зариф
36. Галимов Нургали Хәмәтгали улы
37. Галимов Гарифулла Ибраһим улы
38. Галимуллин Нигъмәтулла Галимулла улы
39. Гәрәев Шәрәфетдин Гәрәй улы
40. Гәрәев Фәйзрахман Гәрәй улы
41. Гәрәев Баһау Гәрәй улы
42. Гәрәев Хәбибрахман Фәйзрахман улы
43. Гобәйдуллин Хәмидулла Гобәйдулла улы
44. Гыззәтуллин Зиннәтулла Габидулла улы
45. Гыйззәтуллин Ибраһим Хафиз улы
46. Газизуллин Рәхимулла Газизулла улы
47. Гатауллин Газиз Гатаулла улы
48. Гатауллин Хәкимулла Гатаулла улы
49. Гәрәев Закир Гәрәй улы
50. Гомәрев Әсләхетдин Фәттахетдин улы
51. Ганиев Кави Гани улы
52. Гәрәев Гали Гәрәй улы
53. Гыйльметдинов Фәсхетдин Гыйльметдин улы
54. Гыйльметдинов Хөснетдин Гыйльметдин улы
55. Гобәйдуллин Мөхлисулла Гобәйдулла улы
56. Зәйниев Фәләх Зәйни улы
57. Зәйниев Таһир Зәйни улы
58. Закиров Хәмәтсабир Закир улы
59. Закиров Әхмәтгәрәй Закир улы
60. Закиров Гомәр Закир улы
61. Заһидуллин Ситдыйк Заһидулла улы
62. Закирҗанов Рәхимҗан Закирҗан улы
63. Зәйнуллин Фәйзрахман Зәйнулла улы
64. Заһидуллин Фәйзелгаян Заһидулла улы
65. Идрисов Гайфетдин Идрис улы
66. Идрисов Гыйниятулла Идрис улы
67. Ибраһимов Миңлемулла Ибраһим улы
68. Исмәгыйлов Исхак Исмәгыйль улы
69. Йосыпов Нәҗип Йосып улы
70. Йосыпов Садыйк Йосып улы
71. Кадыйров Габделхак Кадыйр улы
72. Кадыйров Гаяз Кадыйр улы
73. Кадыйров Миңлегалим Кадыйр улы
74. Кәримуллин Миңлемулла Кәримулла улы
75. Кәримуллин Галиәхмәт Кәримулла улы
76. Кәримуллин Габдулла Кәримулла улы
77. Кәримуллин Минемулла Кәримулла улы
78. Кәшәфиев Фәйзрахман Кәшәфи улы
79. Кәшәфиев Рәхимулла Кәшәфи улы
80. Кәримов Бари Кәрим улы
81. Кәримов Әбүбәкер Кәрим улы
82. Кәримуллин Әсхәдулла Кәримулла улы
83. Кәримуллин Ярулла Кәримулла улы
84. Латыйпов Хәммәт Латыйп улы
85. Латыйпов Шәриф Латыйп улы
86. Мөхәммәтҗанов Рәхимҗан Сабирҗан улы
87. Мөхәммәтҗанов Салихҗан Сабирҗан улы
88. Мифтахетдинов Кашафетдин Мифтахетдин улы
89. Мөхлисуллин Рәхи Мөхлисулла улы
90. Мөхлисуллин Габделбәр Мөхлисулла улы
91. Минһаҗев Фәттахетдин Минһаҗетдин улы
92. Максутов Шәриф Максут улы
93. Максутов Миңлегали Максут улы
94. Мифтахиев Габденнасыйр Закир улы
95. Мөхәммәтҗанов Галимҗан Мөхәммәтҗан улы
96. Мөхәммәтҗанов Гыйльман Мөхәммәтҗан улы
97. Мөхәммәтҗанов Рәхимҗан Мөхәммәтҗан улы
98. Мөхәммәтгалимов Гариф Мөхәммәтгалим улы
99. Мөхетдинов Гайфетдин Мөхетдин улы
100. Мөхетдинов Газизулла Мөхетдин улы
101. Мөхәммәтшин Гарифулла Мөхәммәтша улы
102. Мөхәммәтшин Хәйрулла Мөхәммәтша улы
103. Мөхәммәтшин Кәрим Мөхәммәтша улы
104. Мөхлисуллин Зиннәт Мөхлисулла улы
105. Мөхлисуллин Галимулла Мөхлисулла улы
106. Мөхлисуллин Мөбарәкша Мөхлисулла улы
107. Мөхлисуллин Габдулла Мөхлисулла улы
108. Мөхлисуллин Әсхәдулла Мөхлисулла улы
109. Мотыйгуллин Миңлемулла Мотыйгулла улы
110. Мәгъсүмов Нургали Мәгъсүм улы
111. Мәгъсүмов(Закиров) Кәшиф Мәгъсүм улы
112. Нигъмәтҗанов Мөбарәкҗан Нигъмәтҗан улы
113. Нигмәтҗанов Нургали Нигмәтҗан улы
114. Рәхмәтуллин Әхмәдулла Рәхмәтулла улы

115.Рәхмәтуллин Зәкиулла Рәхмәтулла улы
116.Рәхмәтуллин Гатаулла Рәхмәтулла улы
117.Рәҗәпов Рәхимулла Рәҗәп улы
118.Рәҗәпов Гафиятулла Рәҗәп улы
119.Рамазанов Ибәтулла Рамазан улы
120.Рамазанов Галимулла Рамазан улы
121.Сәмигуллин Салихҗан Сәмигулла улы
122.Сәмигуллин Әхмәдулла Сәмигулла улы
123.Сәмигуллин Рәхимулла Сәмигулла улы
124.Сәмигуллин Рәхимулла Сәмигулла улы
125.Сәмигуллин Рәхмәтулла Сәмигулла улы
126.Сабирҗанов Галимҗан Сабирҗан улы
127.Сабирҗанов Салихҗан Сабирҗан улы
128.Сабирҗанов Хөсәен Сабирҗан улы
129.Сабирҗанов Закирҗан Сабирҗан улы
130.Сабирҗанов Хәкимҗан Сабирҗан улы
131.Сабирҗанов Галимулла Сабирҗан улы
132.Садриев Гайфетдин С.улы
133.Сафиуллин Галимулла Сафиулла улы
134.Сафиуллин Мөхәммәтҗан Сафиулла улы
135.Сөләйманов Сәлимҗан Галимҗан улы
136.Сәләхетдинов Гайфетдин Сәлахетдин улы
137.Саттаров Габдулла Саттар улы
138.Саматов Нәкыйп Самат улы
139.Сәйфуллин (Хәсәнҗанов) Нәфыйк Хәсән улы
140.Сабиров Габдулла Сабир улы
141.Усманов Гыйльман Усман улы
142.Усманов Ногман Усман улы
143.Шакиров Габделхәй Хәйрулла улы
144.Шакиров Хәммәтзакир Шакир улы
145.Шакиров Назыйр
146.Шакиров Хәким Шакир улы
147.Шаһиев Хәйретдин Шаһи улы
148.Шакиров Рәхмәтулла Шакир улы
149.Шәмсетдинов Габдрахман Шәмсетдин улы
150.Шәмсетдинов Хисаметдин Шәмсетдин улы
151.Шәрипов Ситдыйк Шәрип улы
152.Шәрипов Газизулла Шәрип улы
153.Шәрипов Рәхимулла Шәрип улы
154.Шәрәфиев Гарәфетдин Шәрәфетдин улы
155.Шәфигуллин Гайфулла Шәфигулла улы
156.Шәфигуллин Хәмидулла Шәфигулла улы
157.Шәфигуллин Габделяппар Шәфигулла улы
158.Фазылов Шакир Фазылҗан улы
159.Фатыйхов Закирҗан Фатыйх улы
160.Фатыйхов Йөзмөхәммәт Фатыйх улы
161.Хәйруллин Абдулла Хәйрулла улы
162.Хәйруллин Габдулла Хәйрулла улы
163.Хәйруллин Галимулла Хәйрулла улы
164.Хәсәнҗанов Муллахмәт Хәсәнҗан улы
165.Хәсәнҗанов Габделхәй Хәсәнҗан улы
166.Хәсәнҗанов Әгъләмҗан Хәсәнҗан улы
167.Хәкимов Ситдыйк Хәким улы
168.Хаҗиев Галиәхмәт Хаҗиәхмәт улы
169.Хуҗин Хәйретдин Хаҗиәхмәт улы
170.Хуҗин Гайфетдин Хаҗиәхмәт улы
171.Хөрәмшин Җиһанша Хөрәмша улы
172.Хәкимуллин Рәхимулла Хәкимулла улы
173.Хәйруллин Гарифулла Хәйрулла улы
174.Хәйруллин Галиәхмәт Хәйрулла улы
175.Хәкимҗанов Абдулла Хәкимҗан улы
176.Хәкимҗанов Габидулла Хәкимҗан улы
177.Хисмәтов Нәфыйк Кәримулла улы
178.Хәбибуллин Салихҗан Хәбибулла улы
179.Хәбибуллин Абдулла Хәбибулла улы
180.Хәбибуллин Хәләфетдин Хәбибулла улы
181.Хәммәтдинов Сәлахетдин Хәммәтдин улы
182.Хәлимов Нигъмәтулла Хәлим улы
183.Хәлиуллин Гарифулла Хәлиулла улы
184.Хәлиуллин Кәримулла Хәлиулла улы
185.Хәйруллин Хөснулла Хәйрулла улы
186.Хәбибуллин Фәйзерахман Хәбибулла улы
187.Хәбибуллин Каюм Хәбибулла улы
188.Хәбибуллин Гыйният Хәбибулла улы
189.Хисмәтов Сәлахетдин Хәлиулла улы
190.һадиев Нәбиулла Һади улы
191.Яхин Нургали Садрислам улы
192.Яруллин Габделхәй Ярулла улы

## Тәмәй авылы буенча:

1. Әхмәтҗанов Мөбарәкҗан Әхмәтҗан улы
2. Әлтәпов Зыятдин Әлтәф улы
3. Бәдретдинов Шәйхетдин Җамалетдин улы
4. Вәлиев Гарифулла Вәли улы
5. Вәлиев Әхмәдулла Вәли улы
6. Габдерәшитов Гыйльмулла Габдерәшит улы
7. Габдерәшитов Рәхимулла Габдерәшит улы
8. Габдрахманов Латыйп Шәриф улы
9. Габдерәшитов Мәгъсүм Мәҗит улы
10. Гыйльметдинов Гафиятулла Гыйльметдин улы
11. Гыйльметдинов Фәттахетдин Гыйльметдин улы
12. Дәүләтшин Габделәхәт Әхмәт улы
13. Зарипов Таһир Зариф улы
14. Закиров Гариф Закир улы
15. Кадыйров Шаһабетдин Нәҗметдин улы
16. Мәннанов Нәбиулла Мәннан улы
17. Мөлеков Әхмәтшәриф Муса улы
18. Мөлеков Мәгъсүм Муса улы
19. Сираҗиев Хәйретдин Сираҗи улы
20. Сираҗиев Билалетдин Сираҗи улы
21. Сәйфуллин Сәйфетдин Сәйфулла улы
22. Сәйфуллин Мансур Шәфигулла улы
23. Фәттахов Бари Фәттах улы
24. Фәттахов Габделхак Фәттах улы
25. Фәттахов Моталлап Фәттах улы
26. Исмәгыйлов Мөхлисулла Исмәгыйль улы
27. Ибраһимов Шакирҗан Ибраһим улы
28. Ибраһимов Закирҗан Ибраһим улы
29. Низамиев Шиһабетдин Низами улы
30. Низамиев Гайфетдин Низами улы
31. Хуҗиәхмәтов Нуриәхмәт Хуҗиәхмәт улы
32. Хафизов Хәбибулла Хафиз улы
33. Хәсәнов Нәбиулла Хафиз улы
34. Шакиров Габделхәй Шакир улы
35. Шәмсетдинов Фәттәхетдин Гыйльметдин улы
36. Шәмсетдинов Гафиятулла Гыйльметдин улы
37. Шәмсетдинов Шәфигулла Гыйльметдин улы
38. Шәмсетдинов Гыйлаҗетдин Гыйльметдин улы
39. Шәмсетдинов Гомәр Гыйльметдин улы
40. Шәфигуллин Нигъмәтулла Шәфигулла улы